ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 3 өлешендәге өченче абзацында «хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән илле мең мәртәбәгә артыграк» сүзләрен «дәүләт унитар предприятиесе устав фондының федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән 10 тапкырдан күбрәккә артыграк» сүзләренә алмаштырырга;

2) 11 статьяның өченче абзацында «хезмәт өчен түләүнең федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән илле мең тапкырдан артып китсә» сүзләрен «гавами җәмгыятьнең устав капиталының федераль законда билгеләнгән минималь күләменнән 50 тапкырдан күбрәккә артып китсә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 1 өлешендәге икенче абзацында «шушы тәкъдимне керткән дәгъвачы» сүзләрен «шушы тәкъдимне җиткергән дәгъвачы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 84-ТРЗ